ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

12.12.2017 г. Казань № 150-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 13.09.2016 № 069-од боерыгы белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы белән расланган нигезләмәгә һәм Федераль дәүләт органының кадрлар резервы турында Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 1 мартындагы № 96 Указы белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 10 сентябрендәге № 419 Указы нигезендә б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәне раслау хакында» 13.09.2016 № 069-од боерыгы белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 1.3. пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның шушы вазыйфа өчен квалификацион таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләүдән гыйбарәт.»;

3.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Конкурста катнашу өчен документлар кандидатлар тарафыннан Дәүләт комитетына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында документларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән 21 календарь көн эчендә шәхсән, почта аша җибәреп яисә, күрсәтелгән мәгълүмат системасын файдаланып, электрон рәвештә тапшырыла. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) Дәүләт комитетына кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге 4 нче кушымтада бирелә.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яисә мәгълүм сәбәпләрсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру аларны гражданнан (граждан хезмәткәреннән) кабул итүдән баш тарту өчен нигез була.

Документлар мәгълүм сәбәп буенча вакытында тапшырылмаганда, алар тулы булмаган күләмдә яисә аларны рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылганда яллаучы вәкиле аларны кабул итү срокларын күчерергә хокуклы.»;

Нигезләмәнең 3.3. пунктының үз көчен югалтуын танырга;

3.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, Дәүләт комитетында конкурста катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре Дәүләт комитеты рәисе исеменә язган шәхси гаризасын һәм үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм граждан хезмәткәре вазыйфа били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган анкетасын Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе белән расланган рәвеш буенча, фотографияләрен кушып, Дәүләт комитетына тапшыра.»;

4.4.1. пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.1. Беренче этапта Дәүләт комитетының һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервы формалаштырыла торган вазыйфаның) атамасы, шушы вазыйфаны биләү өчен белдерелә торган квалификацион таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар Дәүләт комитетына тапшырырга тиешле документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә документларны һәм материалларны кабул итү урыны һәм вакыты (4 нче кушымта), әлеге документларны кабул итү вакытының тәмамлану срогы, конкурсны уздыруның күз алдында тотылучы датасы, конкурс уздыру урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар.»;

4.4.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган документларны тикшергәннән, Дәүләт комитетының кадрлар резервына керткәннән соң хокукый һәм кадрлар эше бүлеге документларны кабул итү тәмамланган көннән гражданнарны (граждан хезмәткәрләрен) конкурста катнашуга кертүгә рөхсәт бирү турында карар кабул итү

өчен йә конкурста катнаштырудан дәлилләнгән баш тарту өчен Дәүләт комитеты рәисенә тәкъдим кертә.

Конкурсның икенче этабын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы карар граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшергәннән соң, шулай ук дәүләт серен һәм бүтән закон белән сакланылучы серне тәшкил итүче белешмәләрне алуны рөхсәт итү кирәк булган очракта, аларны рәсмиләштергәннән соң, Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан кабул ителә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланган көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла, дәүләт серен һәм бүтән закон белән сакланылучы серне тәшкил итүче белешмәләрне алуны рөхсәт итү кирәк булган очракта, конкурсның икенче этабын уздыру срогы Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килерлек хәлләр ачыкланганда, яллаучы вәкиле конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында аңа язма рәвештә хәбәр итә. Әгәр граждан конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турындагы хәбәрнамә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салып, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, аңа электрон документ рәвешендә җибәрелә.»;

4.4.5. пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хокукый һәм кадрлар эше бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көн кала, конкурс уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүматны, конкурста катнашуга кертелгән гражданнар (граждан хезмәткәрләре) (алга таба – кандитатлар) исемлеген үзенең рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыра һәм кандидатларга язма рәвештә тиешле хәбәрләрне җибәрә, бу чакта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, әлеге мәгълүматны, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салып, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрә.»;

4.9. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр кандидатларга конкурс тәмамланган көннән соң 7 көнлек срокта язма рәвештә җибәрелә, бу чакта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салып, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат шул ук срокта Дәүләт комитетының һәм «Интернет» челтәрендә күрсәтеләгән мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштырыла.»;

4.10. пунктка түбәндәге эчтәлектә икенче абзац өстәргә:

«Конкурста катнашучы өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар хокукый һәм кадрлар бүлегендә өч ел буена саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.»;

Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 1.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче, дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә законнар белән билгеләнгән квалификацион таләпләргә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары ия була.»;

Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. «Җитәкчеләр» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфаларын, югары һәм төп төркемнәр граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен специалитет, магистратура дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белем булу мәҗбүри.

2.2. «Җитәкчеләр» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфаларын, әйдәүче төркеме граждан хезмәте вазыйфаларын, граждан хезмәте әйдәүче төркеменең «белгечләр» категориясендәге вазыйфаларын биләү өчен югары белем булу мәҗбүри.

2.3. Татарстан Республикасы граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәкле граждан хезмәте яисә белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификацион таләпләр Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

2.4. Вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле белемнәренә һәм күнекмәләренә карата квалификацион таләпләр граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә аның вазыйфаи регламенты белән билгеләнә. Граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламенты белән шулай ук граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кирәкле белгечлегенә, әзерлек юнәлешенә карата квалификацион таләпләр дә каралырга мөмкин.»;

Нигезләмәгә 4 нче кушымтаның 1 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) тутырылган һәм имзаланган анкетасын, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча, фотографиясен кушып;»;

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова